**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет Азнакаевского муниципаль районы**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты**

Ленин ур., 22 й., Азнакай ш., 423330
Тел./факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

Ленин урамы, 22 йорт, Азнакай шәһәре, 423330
Тел./ факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

**"14" июль 2022 ел** **№ 192**

Азнакай муниципаль районы башкарма комитетының 2021 елның 30 декабрендәге 342 номерлы «Азнакай муниципаль районы башкарма комитетының сатып алулар секторына аерым вәкаләтләр һәм функцияләр йөкләү турында» карары белән расланган, заказчыларның муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә тәэмин итүчеләрне (подрядчыларны, башкаручыларны) билгеләү вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы вәкаләтле орган белән үзара эшчәнлек тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 16 апрелендәге 104-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә карар бирә:

1. Азнакай муниципаль районы башкарма комитетының 2021 елның 30 декабрендәге 342 номерлы «Азнакай муниципаль районы башкарма комитетының сатып алулар секторына аерым вәкаләтләр һәм функцияләр йөкләү турында» карары белән расланган, заказчыларның муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә тәэмин итүчеләрне (подрядчыларны, башкаручыларны) билгеләү вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы вәкаләтле орган белән үзара эшчәнлек тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 пунктның 1.5 пунктындагы 4 абзацында «Салым кодексының 284 статьясындагы 3 пунктының 1 пунктчасы» сүзләрен «Бюджет кодексының 241 статьясындагы 15 пункты» сүзләренә алмаштырырга, «салым салуның ташламалы салым режимы һәм (яисә) юридик затларга карата финанс операцияләре (офшор зоналары) уздырганда мәгълүмат ачуны күздә тотмый торган» сүзләрен «Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен кулланыла торган» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарның 1.1 пунктчасы 2023 елның 01 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырырга түбәндәге веб-адрес буенча бастырырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга: http://aznakayevo.tatar.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад һәм финанс буенча урынбасары О.Н. Газизовага йөкләргә.

Җитәкче А. Х. Шәмсетдинов